МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТОЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.07.2017 г.Казань № 152/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибе турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 олешенең 3 пункты нигезендә

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рохсәт бирүнең тәкъдим ителгән тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары О.В. Земсковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр М.Г. Әхмәтов

Утвержден
приказом Министерства
сельского хозяйства и
продовольствия
Республики Татарстан
от 10.07.2017 № 152/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциягә карамаган оешма) белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү процедурасын регламентлаштыра.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында эш бирүче вәкиле Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры булган (алга таба – Министр) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә карата кулланыла.

2. Коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча язма рәвештә бирелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциягә караган һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карап тикшерә һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Җаваплы зат Гаризаны алдан карау барышында Гариза биргән граждан хезмәткәреннән коммерцниягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә планлаштырыла торган катнашу буенча язма аңлатмалар һәм функцияләрне билгели торган документлар соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Җаваплы зат Бәяләмә һәм башка материаллар (булган очракта) беркетелгән Гаризаны, Гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү яки рохсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) каравына кертә.

Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гариза алган көннән ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткән көннән алып ике эш көне эчендә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында граждан хезмәткәренә хәбәр итә һәм аңа, кул куйдырып, Министр резолюциясе салынган Гаризаның кадрлар бүлеге мөһере куелган күчермәсен тапшыра. Министр резолюциясе салынган Гаризаның төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси делосына беркетелә.

\

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

______________________________________

______________________________________

(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм структур

______________________________________

бүлеге, яшәү урны адресы

______________________________________

телефон номеры)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү турында
гариза

Миңа ____________________________________________________________
иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек,

________________________________________________________________
дача кулланучылар кооператив, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте)

белән идарә итүдә түләүсез______________________________________________.
(бер кешедән гыйбарәт башкарма органның яки коллегиаль идарә органының исеме)

буларак катнашырга, идарәнең коллегиаль органы составына керергә (тиешлесенең астына сызарга) рөхсәт бирүегезне сорыйм.

______________ _________________ ______________________________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез бер кешедән гыйбарәт башкарма орган буларак катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эш бирүче вәкиле тарафыннан рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| т/б № | Дата | гарызнамә бирүченең Ф.И.А.и., вазыйфасы | Гарызнамә бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.А.и., | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |